**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№2** **26.11.2020**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Микулино  авыл җирлеге составына керүче,
Александровка  авылында 2021 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Александровка авылы гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Микулино авыл җирлеге Александровка торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 175 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:
- Александровка авылында юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы И.А.Такиулин